**Торак пунктта гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге составына керүче Кызыл Чишмә авылы**

**2025 елның 24 октябре № 2**

**Кызыл Чишмә ав., Октябрь ур., 26 й.**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Кызыл Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кызыл Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган 1 төркем инвалидлардан, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган күпбалалы гаиләләрдән срочная хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, 500,00 сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Октябрь ур. буенча ВКПС юлын салу)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**«Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы**

**Г. Ә. Хәйсарова**